Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Камай авыл җирлеге составына керүче
Камай авылында
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

25.11. 2023 ел № 2

2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенең Камай авылы гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Камай авылы җирлегенең Камай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләреннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, билгеләргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

1.Кышкы чорда юлларны кардан чистарту;
2.Җәйге вакытта үләннән территорияне чабу;
3.Авыл исеме белән стелла сатып алу һәм урнаштыру;
4.Спорт мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру;
5.Урам яктырту челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү;
6.Таш сатып алу, китерү, тигезләү;
7.Чүп контейнерларын сатып алу;
8.Трибуна һәм ял зонасы белән сәхнә ясау һәм урнаштыру;
9.Ясалма тигезсезлекне алу һәм урнаштыру.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Камай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Камай авыл җирлеге башлыгы И.М. Ахунҗанов